Республика Татарстан
**Исполнительный комитет**
**Тураевского сельского поселения**
Менделеевского муниципального района
423647 Менделеевский район, с. Тураево
ул. Центральная 11 а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
**Турай авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**
423647 Менделеевск районы, Турай авылы
Үзәк ур. 11 а й.

Тел. (факс): (85549) 3-60-31
e-mail: Tur.Men@tatar.ru

---------------------------------------------------------------------------------------------------

**КАРАР**

№ 7 09.10.2023 ел

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
«Турай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең Генераль планына
үзгәрешләр кертү проекты буенча
гавами тыңлауларны игълан итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Турай авыл җирлеге уставы, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 9 ноябрендә 14 сәгатьтә Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегендә Менделеевск районы, Турай авылы, Үзәк ур., 11А йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәктә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Куляшова Г.Б. - Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Шәймөхәммәтов Р.Р. - Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге рәисе урынбасары;

Вәлиев Ф.Г. - Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге депутаты (килешү буенча).

3. 2023 елның 9 октябреннән 2023 елның 9 ноябренә кадәр «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты материаллары экспозициясен Менделеевск муниципаль районы күпфункцияле үзәк бинасында (Менделеевск районы, Турай авылы, Үзәк ур., 11А) оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 432647, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Турай авылы, Үзәк ур., 11А йорт (Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Турай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б. Куляшова